ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Старокамкинского сельского
поселения Алькеевского
муниципального района

Адресы: 422897, ТР, Әлки
районы, Иске Камка авылы,
Түбән урамы,1
тел./факс 8(84346) 73-524

Адрес: 422897, РТ, Алькеевский
район, с. Старое Камкино,
ул.Нижняя.д.1
тел./факс 8(84346) 73-524

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Камка авылы **КАРАР**

**2023 елның 22 марты** **14№**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмеш лампаларын туплау урыны (урыннары) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү хакында

1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ номерлы, 2002 елның 10 гыйнварындагы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 7-ФЗ номерлы, 2009 елның 23 декабрендәге «Энергияне сак тоту турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 261-ФЗ номерлы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге «Гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткычлар, электр лампалары өлешендә, җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2314 номерлы карары нигезендә, Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы, Әлки районы, Иске Камка авылы, Үзәк урамы, 5 йорт (склад бинасы)адресы буенча кулланылган терекөмеш лампаларын туплау урынын (урыннарын) билгеләргә.

2. Күпфатирлы йорт милекчеләре, яллаучы, күпфатирлы йортлардагы урыннардан файдаланучылар кулланылган терекөмешле лампалар туплау урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә,

хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткычлар, электр лампалары өлешендә, җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру белән эш итү кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән урынны кулланылган терекөмеш лампаларын туплау урыннары шул исәптән, күпфатирлы йортларда терекөмешле лампалар туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле аларны туплау мөмкин булмаганда, күпфатирлы йорт милекчеләре, яллаучы, күпфатирлы йортлардагы урыннардан файдаланучылар кулланылган терекөмешле лампаларны туплау урыны итеп билгеләнгәнлеген билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплау урыны турында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында (стойкаларында) мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга мәгълүмат бирергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының район массакүләм мәгълүмат чарасында (htth:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 19 сентябрендәге 13 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Ф.А.Акберов